Чыганак: Сәхнә. – 2003. – №1. – Б. 4–5



Бу фоторәсемнән безгә, үзләреннән соң киләчәк буыннарга гасырлар чоңгылыннан «Сәйяр» труппасы актерлары мәгърур күз карашларын төбәгән. Алар (сулдан уңга): Фәхрия Әхмәдова-Ашказарская (1880-1956), Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская (1892-1974), Барый Болгарский (1884-1927), Вәли Мортазин-Иманский (1885-1938), Фәхрениса Сәмитова (1890-1939); (басып торучылар), Габдулла Кариев (1886-1920), Нури Сакаев (1885-1927). Бүген бу тарихи гүзәл фоторәсем Г.Камал театрының иң түрендә балкып тора. Берданбер көнне әлеге фото җанланып китте, һәм андагы актерлар үзара әңгәмә корып җибәрделәр...



Луара ШАКИРҖАН

# «Без шундый театр төзербез!..»

**Кариев.** Тулы... тулы!..
**Нурый.** Шыгрым тулы...
**Сәмитова.** Дөрес күрәбезме соң?.. Татар театрымы бу?
**Вәли.** Дөрес. Йа Алла, сөбханалла, күз тимәсен.
**Барый.** Гаҗәп!..
**Волжская.** Нәрсәсе гаҗәп, Барый, без аның шулай буласын белдек!
**Барый.** Юк инде, Сәхипҗамал, шикләнгән чаклар да аз булмады. Бездән башка бу милли театр кемгә кирәк соң, дигән өметсез чаклар күп булды бит.
**Кариев.** Ничек кемгә! Халыкка кирәк! Мин аны Мәкәрҗәдә үк, Ашказарскийның Ырынбурдан килгән беренче гастрольләре вакытында да тойдым. Безнең халык театрны сөя, сөячәк. Татар бит ул хискә бай, җырлый да, җылый да.
**Вәли.** Тукай әйтмешли, моңлы ул, бөек ул, диген.
**Кариев.** Эх, җаннарым, безнең тырышлыклар, газапларыбыз бушка китмәгән!

**Барый.** Кара әле, димәк, без башлаган эш дәвам итә?
**Волжская.** Әйе, зал буш булмагач, димәк, бушка түгел. Күр, алма төшәр урын юк.
**Сәмитова.** Әй Сәхипҗамалым, ә кайчан без буш залга уйнадык?
**Волжская.** Син соңрак килдең, Фәхрениса, белмисең. Җен шаукымы таратасыз, дип, янап, куркытып, безне дә, килгән халыкны да таратулар күп булды. Я цензор тыйды, я кадимчеләр куды. Теңкәгә күп тиделәр.
**Сәмитова.** Әйе, син елаганны күргәч, Тукай үзе сиңа шигырь багышлаган...
**Вәли.** Ә-ә, кояш белән тиңләпме?« Бу икәүгә Ходай биргән бер тигез зур мәртәбә, берсе – күктә, икенчесе – сәхнәдә..».
**Нурый.** Юк, Сәхипҗамал спектакльдән кайтканда, аны ташлар белән кыйныйлар, ул чак үлми котылып кала, бу хәлне Тукай ишетә.
**Әхмәдова.** Сөйлә әле шул шигырьне, Сәхипҗамал.
**Волжская.** «Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын.
Без үләрбез, билгеле, тик үкенечкә калмасын.
Киң күңелле бул эчеңнән, мыскыл ишетсәң вак диген,
Таптасыннар, хурласыннар, тик җаның хурланмасын.»
Бу шигырь минем гомерем буена маяк булды. Тукай биргән чәчәкләрне хатирә итеп озак йөрттем. 18 нче елларда гына саклый алмадым.
**Нурый.** Ул елларда чәчәк түгел, баш саклавы да авыр булды.
**Барый.** Габдулла башына да кара тап булып төште ул аклар тамгасы. Аклы-кызыллы яман чор. Ничек борчылдык без синең өчен, белсәң, Габдулла.
**Кариев.** Әйе, күрде инде безнең башлар барысын да. Себердә дә, монда да. Гастрольләрдә ике көнгә бер ашап, бер телемне бишкә бүлеп, төн йокламый, аяк-борын өшетеп килсәк тә, сәхнәгә менгәч, барысын онытa идек.
**Вәли.** Эх, ул бәхетле мизгелләр!
**Сәмитова.** Яшьләр идек шул. Ә исегездәме, Мәскәүдән поезд белән кайтканда, берчак качып-посып билетсыз утырдык.
**Кариев.** Бер тиен акча юк иде.
**Нурый.** Аннан куып төшерделәр.
**Волжская.** Коточкыч салкын иде, туңып үлә яздык.
**Барый.** Ә Габдулла колагына бияләй киде, исегездәме, шул килеш әле станца начальнигына керде.
**Вәли.** Ә ул татар иде бугай.
**Нурый.** Әйе, әйе, Карыйның Коръәнне яттан белүен әйтеп, довериесенә кергәч кенә поездга утырттылар.
**Барый.** Шул-шул, Коръән-Хафиз башлады бит ул театр эшен. Бисмилла белән. Шуңадыр, җиңелмәдек.
**Кариев.** Без, «Сәйяр»леләр, бергә башладык бу эшне. Мин – сезне, тамашачыны, тормышны, бер ноктага җыючы гына.
**Әхмәдова.** Син гайрәтле идең; сәясәтле, дәртле татарлардан бердәнбер сәхнә эшчесе идең. Кәрим синең турыда шулай әйтте.
**Кариев.** Тинчурин үзе дә безнең күз алмабыз, театрны өзелеп сөюче артист, режиссер, драматург иде.
**Вәли.** Синең шәкерт инде, Карый. Син бит сәләтлеләрне әллә каян күреп, танып ала идең, үгетли, ышандыра белә идең. Талантын ача идең.
**Барый.** Юкка гына сине үзең исән чакта ук татар театрының атасы дип атамадылар. Син пәйгамбәр күк идең.
**Кариев.** Миңа да бик авыр иде. Театр турында, артистлар, репертуар, бина, матди якларны уйлап төннәрем йокысыз үтә иде. Бигрәк тә син, Сәхипҗамал, беренче артисткабыз, «Сәйяр»не ташлап, Уфага киткәч, театр таркалыр дип курыктым.
**Волжская.** Нигә алай? Минем урында сәхнә йолдызы Гөлсем бар иде инде. Болгарская. Аннан Фатыйма Ильская килде. «Сәйяр»нең яшәренә иманым камил иде. Шуңа да яңа труппа – «Нур»ны оештырдым.
**Кариев.** Шулай. Безнең дуслар шәп иде. Алар театрның терәге булды. Камалсыз ун ел буе нәрсә уйнар идек?
**Волжская.** Гаиләсгар әфәнде безгә әсәрләре белән генә түгел, уены, хәтта киемнәре белән булышты. Ә игъланнарны үз кулы белән ничек матур яза иде.
**Барый.** Ә Гаяз, Сәгыйть, Мулланур, Гафур, Фәтхи?..
**Вәли.** Фатыйхны – Әмирханны онытмагыз!
**Әхмәдова.** Ә Тукай, ул инде бөтенләй безнең «Сәйяр»неке иде.
**Вәли.** Үзе тапты бит «Сәйяр» исемен дә.
**Кариев.** Без Тукай белән Уральскида бер бүлмәдә торып, тәмам туганлаштык. Адашымның яшьли вафаты мине дә сындырды. Шул чакта тавышсыз калып, авырып йөрүем исегездәдер. Бу башы иде...
**Волжская.** Сез барыгыз да яшьли киттегез. Тукайдан соң җиде елдан син, Карый, тагын җиде елдан син, Нури, аннан Барый, Вәли...
**Нурый.** Кариевның соңгы юлы шау-шусыз булды, күпләр килмәде, шүрләделәр бугай.
**Волжская.** Ә, сине Нури, олылап озаттылар. Матәмеңә Сәйдәш бер төн эчендә Сакай маршы язды. Ә син, Габдулла, үзеңне саклый ала идең, бит! 18 нче ел мәхшәрендә күп зыялыларыбыз китте. Гаяз Исхак кебек читтә булсалар да, милләт дип яндылар, яздылар, син дә яшәгән булыр идең,... Китмәдең шул...
**Кариев.** Язучы, каләме булса, кайда да яза ала. Ә мин сезсез, сәхнәсез, берүзем – үземә дә кирәкмәдем. Мин бит театр өчен генә яшәдем. Хәтта аклар чолганышында да мин любительләр белән «Зөләйха»ны куйдым.
**Вәли.** Шуңа күрә, имеш, халык дошманы булдың.
**Әхмәдова.** Әй, Вәли, Вәли Мортазин-Иманский, сиңа да шул мөһерне суктылар, 37 нче дә. Ә үзең Ырынбурда «Ширкәт» труппасы оештырып, милләт өчен янып йөрүче кыю кеше идең.
**Волжская.** Бер Вәли генә түгел, Кәримне дә, Борнаш, Мутин кебек асыл зыялыларны да юк иттеләр. Хәер, ачлык, салкын да безнең башларга иртә җитте. Мин дә авыруым сәбәпле театрда озак эшләмәдем. Ә шулай да озак яшәдем. Безгә багышланган «Гөлҗамал» спектаклен дә күрдем әле мин... Нәкый энекәш язган иде аны...
**Сәмитова.** Мин дә «Сәйяр»дән Сәхипҗамал белән бергә Уфага киттем. Туфрагым тарткандыр. Төрле театрларда эшләдем. 50гә дә җитә алмадым. Кыска булды гомер.
**Әхмәдова.** Ә без Ашказарский белән бергә һәвәскәр театрлар оештырдык. Безне әле 26 нчы елда Нури, Барыйлар белән бергә хезмәт батыры да иттеләр. Шул ук елны татар театрына Академия исемен, ә 39 нчы елда Камал исемен бирделәр. Театр Мәскәүгә декадага баруы турында ишеткәндә исән идем, алар йөреп кайтканда мин дә юк идем...
**Волжская.** Дан казаньп кайткан, диделәр.
**Нурый.** Әйе, бер театрны бердәй яратсак та, язмышларыбыз төрле булды.
**Вәли.** Ә театр барыбер яши бит!
**Волжская.** Яши! Гәрчә артистларга һәр чорда кыен булды, аларга бүген дә җиңел түгел. Безнең шикелле үк акчасызлар. Без әле дәрәҗәлерәк тә идек бугай...
**Кариев.** Театр ул – фанатиклар эше. Театр ул – могҗиза. Аның хакына, менә шундый тулы зал хакына барсына да түзеп була. Шулай, җаннарым, әйткән идем бит сезгә: без әле шундый театр төзербез, аның исемен алтын хәрефләр белән язарлар дип. Сүзем хак булган. Нәкъ Шәрык клубы каршында татар театрының без хыялланган үз бинасы да бар. Театрга тиздән 100 ел тулачак. Киләчәктә дә безнең эшне талантлы яшьләр дәвам итсен. Алар да театрны без яраткан кебек яратсыннар иде!